КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август г.Казань № 731

«Бердәм «112» номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыртуны тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында

Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфатын арттыру, халыкның барлык катламнары өчен аларның һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүче оешмаларга карата таләпләрне стандартлаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Бердәм «112» номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыртуны тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Ашыгыч оператив хезмәтләрне чакырулар буенча мәгълүматлар кабул итү, эшкәртү, мәгълүматлар базаларын формалаштыру һәм алып бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2015 ел, 10 март, 142 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ашыгыч оператив хезмәт күрсәтүләрне кабул итү, эшкәртү, мәгълүмат базаларын булдыру һәм алып бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты стандартын раслау турында» 2015 ел, 10 март, 142 нче карары белән расланган Мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү, мәгълүмат базаларын булдыру һәм алып бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты стандартының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 9 февраль, 75 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ашыгыч оператив хезмәтләрне кабул итү, эшкәртү, мәгълүмат базаларын булдыру һәм алып бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2015 ел, 10 март, 142 нче карары белән расланган Ашыгыч оператив хезмәтләрне кабул итү, эшкәртү, мәгълүмат базаларын булдыру һәм алып бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты

стандартына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 25 декабрь, 1222 нче.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Премьер-министра
Республики Татарстан А.В.Песошин